Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2-256)

Ислам Нуры

№ 2 (630) 26 гыйнвар, 2017 ел (1438, Рабигүл-ахир) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга 12+

# Еллык эш бик тә канәгатьләнерлек дип бәяләнде

Чаллы мәчетләре еллык нәтиҗәләр буенча җыелышлар үткәрүне гадәткә кертте. Алар барышында үткән ел эшчәнлегенә анализ ясала, яңа елга эш планы кабул ителә, мәхәллә әгъзалары составы тулыландырыла. Шундый җыелыш 19 гыйнварда шәһәрнең “Туфан” мәчетендә узды.

Мәчет имам-хатыйбы Равил хәзрәт Нуруллинның чыгышыннан күренгәнчә, узган ел мәчет өчен шактый истәлекле булган. Чөнки 25 сентябрьдә мәхәллә халкы мәчеткә ун ел тулуны зурлап билгеләп үтте. Аңа әзерлек уңаеннан мәчет бинасы тыштан да, эчтән дә төзекләндерелде. Бу эш Диния нәзарәте һәм Чаллы мөхтәсибәте булышлыгы белән башкарылды.

Мәчет коллективы дус, бердәм. Бирредә бик күп матур традицияләр яши. Мәсәлән, мәчетнең иң күркәм бабаен билгеләү, юбилейларны бәйрәм итү, төрле викториналар уздыру, өлкәннәр һәм мохтаҗлар өчен мәҗлесләр үткәрү, мәчетне тәртиптә тоту буенча өмәләр оештыру һ.б. Мәчеттә узган ел Аксакаллар шурасы оештыру да бер яңалык булган. Ул хәзер уңышлы эшли. Мәчеттә якшәмбе укуларына йөрүчеләр саны да арта бара. Быел 83 хатын-кыз һәм 7 ир-ат дини гыйлем ала. Аларга аттестация узган 11 мөгаллим һәм мөгаллимә дәресләр бирә. Мәчет мөхтәсибәт уздырган чараларда актив катнаша. Гает бәйрәмнәре зурлап үткәрелә. Мәсәлән, мәчеткә йөрүчеләр узган корбан бәйрәмендә ике сыерны, унлап сарыкны корбанга чалганнар һәм аның өчтән бер өлешен төрле хәйрия ашлары өчен мәчеткә тапшырганнар.

Мәхәллә әгъзалары Равил хәзрәтнең отчеты белән танышкач башкарылган эшләрне бик тә канәгатьләнерлек дип бәяләделәр. Шулай ук ревкомиссия отчеты тыңланды һәм расланды, мәхәллә составына яңа әгъзалар кертелде. 2017 елга кабул ителгән эш планында мәхәллә территориясендә яшәүче һәм әлеге мәчеткә йөрмәүче картларны мәчеткә тарту, Болгарга сәяхәт кылу, мәчет картларының дәрәҗәсен күтәрү, укуларга ирләрне күбрәк җәлеп итү һ.б. чаралар буенча бурычлар билгеләнгән.

**Рәсемнәрдә:** Равил хәзрәт чыгыш ясый; җыелыш бара.





# Үзешчән футбол командалары Мөхтәсибәт призына көч сынашты

Чаллыда балаларның һәм яшүсмерләрнең үзешчән футбол командалары арасында (10 команда) 4 ай буена кар өстендә барган ярышлары тәгәлләнде. Аларның составында мөселманнар да, православие вәкилләре дә уйнады. Арада мөселманнардан гына торган командалар да бар иде. Һәм менә 22 мартта финал уеннары булды. Анда финалга чыккан 8 команда көч сынашты. Алар ике лигада уйнады. Җиңүче командалар зур кубок, ә җиңелүчеләр кечкенә кубок өчен көч сынаштылар. Уеннар шәһәрнең Гали Акыш исемендәге лицее спорт мәйданчыгында барды. Һәм менә шәһәрнең үзешчән командалары арасында иң көчлесе билгеле булды. Ул югары лигада җиңгән 25 бистә командасы иде. Ул сезон чемпионы булды. Икенче һәм өченче урыннарда “Юность” һәм “Меридиан” командалары. Шулай ук турнирның иң яхшы һөҗүмчесе, сакчысы, ярымсакчысы, җиңүгә омтылуда зур ихтыяр көче күрсәтүчеләре билгеләнде. Җиңүче командалар төрле дәрәҗәдәге кубокларга һәм Чаллы шәһәре Мөхтәсибәте призларына лаек булдылар.

Мондый ярышларны шәһәрнең балалар һәм яшүсмерләр арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы “Меридиан” җәмәгать оешмасы (җитәкчесе дин кардәшебез Марат Илизар улы Гәрәев) мөхтәсибәтнең актив булышлыгы нәтиҗәсендә инде берничә ел оештыра.

**Рәсемнәрдә:** җиңүче команда; турнирда катнашучылар.






# Ризыгыбыз киң булсын

Дөнья — мәктәп. Аллаһ Раббыбыз — Тәрбияче һәм Укытучы. Без барыбыз да Аннан дәрес алучылар. Аллаһ Раббыбыз хикмәт белән һәркөн Үзенең колларына дәрес бирә, бу болганчык дөньяда туры юлны табарга ярдәм итә. Без — дөнья яратылганда җан буларак яратылып, акыл нигъмәте белән нигъмәтләнеп, Җир йөзенә хәлифә булып килгән бәндәләр, тормыш сабакларыннан гыйбрәт алып, үзебезнең хаталарыбызны төзәтеп, пакь-саф хәлдә кабат Аллаһ хозурына кайтырга тиешбез. Беркем дә — баймы ул, ярлымы, зур дәрәҗәлеме, түгелме — җанны үзе теләгән кадәр үзендә тота алмый, Аллаһка кайтарырга тиеш. Җаннарыбызны, кальбләребезне пакьләр өчен безгә Ислам дине бирелде. Бүген дин тотарга, дини белем алырга мөмкинлекләр күп. Әмма без, кызганыч ки, гафиллектән чыгарга ашыкмыйбыз, гөнаһ кылудан чирканмыйбыз. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Хәрам юл белән кергән бер сум акчадан баш тарту мең сум сәдака бирүдән хәерлерәк», — дигән иде. Бүген күбебез, нинди юл белән килүен уйламыйча, мал җыю белән мәшгуль. Барыбыз да байлык туплау марафонына чыккан ярышучылар диярсең. Чабып барганда тын кысылган кебек, кайвакыт Аллаһның нигъмәтләре дә кысылып куя. Аллаһ Раббыбыз Коръәни Кәримдә: «Әгәр Аллаһ һәр кешегә ризыкны киң кылып, һәрберсен бай итсә, ул вакытта, әлбәттә, һәркайсы җир өстендә бозыклык вә фәсәд кылыр иде, шуның өчен кешеләргә малны Үзе теләгәнчә генә бирәдер, Аллаһ, әлбәттә, бәндәләрнең хәлләреннән хәбәрдардер, кемгә күп ризык тиешле, кемгә аз тиешле икәнлекне дә белүчедер» (42:27).

Күп вакыт байлык һәм дәрәҗә кешеләрнең азуына сәбәп була. Хәзрәте Госман  һәм Габдерахман бин Гауф (Аллаһ алардан разый булсын) сәхабәләр арасында иң бай булганнар, ләкин аларда чиктән ашу булмаган, әмма андыйлар бик аз. Ислам галимнәре әйткәннәр: «Берәүнең ышануы байлык белән камәләткә ирешсә, юклык аны харап итәр иде; берәүнеке — юклык белән камәләткә ирешсә, байлык аны харап итәр иде. Берәүнең ышануы сәламәтлек белән камәләткә килсә, авыру аны харап итәр иде; берәүнеке — авыру белән килсә, сәламәтлек аны харап итәр иде». Иман белән үтү өчен кемгә нәрсә кирәген фәкать Аллаһ кына белүче. Кайвакыт борчылып, без кайгырган әйбер безнең өчен нигъмәт була, ә кайвакыт без шатланган, безне сөендергән әйбер безне харап итә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: «Җәннәткә иң соңыннан байлар керерләр. Икенче бер хәдисендә: «Бер сәгать авыру — сырхауга, бераз мәшәкатькә сабыр итү — бер ел нәфел гыйбадәттән артык», — диде.

Бүген Аллаһ Раббыбыз безгә «кризис» дигән дәресен бирә. Газет-журналларда да, радио-телевидениедә дә, урамда да телдән «кризис» дигән сүз төшми. Бер авыл мәчетенә өйлә намазына кергән идем. Намаз тәмам булгач, бер карт: «Хәзрәт, син элек экономист булып эшләгән кеше, безгә кризис турында аңлат әле», — дип мөрәҗәгать итте. Бу хакта Рамил хәзрәт Юнысның вәгазен тыңларга туры килгән иде. Аңа Аллаһның рәхмәте булсын. Аннан ишеткән вәгазьне дә файдаланып, өлкәннәр соравына җавап биреп карыйм. Нәрсә соң ул кризис? Грекчадан «Аллаһның хөкем итүе» дигән мәгънәне аңлата икән. Безнеңчә әйтсәк — Аллаһ Үзенең нигъмәтләрен кысып куеп, безне уйланырга этәрә, безгә дәрес бирә. Аллаһ җирне, күкләрне һәм алар арасында булган барча нәрсәне безнең өчен, адәм баласы өчен яратты, акыл нигъмәте белән нигъмәтләп, безне шул байлыкларга хәлифә итеп куйды. «Әйә күрмисезме, Аллаһ күктә булган кояш, ай, йолдыз- ларны вә җирдә хайваннарны вә табигать байлыгын сезгә файдаландырды, вә сезгә күренгән вә күренмәгән нигъмәтләрен тәмам бирде. Кешеләрдән бәгъзеләре Аллаһ хакында яки Аның дине хакында дәлилсез, белем-сез, мәгърифәт туры булган Коръәннән башка һәм үзе һидаятьсез булганы хәлдә тартышырлар, хакны инкяр итеп вә ялганны яклап»(31:20 14).

Ә безләрне Үзенә гыйбадәт кылыр өчен, ягъни Җир йөзендә Ул кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәр өчен яралтты. Аллаһ Раббыбыз Үзенең нигъмәтләрен кысып куеп, ризыкны киметеп, безнең дөрес яшәмәвебезне исебезгә төшерә. Нигъмәтләре бик күп төрле: ашарга ризык, эчәргә су бирде, сәламәтлек, тәүфыйк, һидаять бирде, иман бирде, Корьән иңдерде, пәйгамбәр җибәрде. Аллаһның нигъмәтләрен санап чыгу мөмкин булмаган кебек, шөкранә кылып бетерү дә мөмкин түгел, чөнки шөкранә кылу — үзе дә Аллаһның нигъмәте. Бүген кайберәүләр «Ислам — авыр дин, тыюлар күп», — дияргә ярaталар. Ә нәрсә тыелган соң, санап карыйк: хәмер, үләксә, бугаз каны, дуңгыз ите, «бисмилләһ» әйтми суелган терлек ите, урлау, зина, отыш уеннары, риба (процент алу), ялган, гайбәт һ.б.ш. Ә нәрсә рөхсәт ителгән — көннәр буе санасаң да, исәбе-хисабына чыгарлык түгел. Бер табында утырганда шундагы ризык төрләрен санарга кушкан идем — кырыкка якын ризык булып чыкты. Ә бу дөнья дигән табын, анда ризык санына чыгарга мөмкин түгел. Ни сәбәп беләндер ризык кимегән икән, әйдә уйланыйк, фикерлик — хатабыз нидә? Бүген дөньяда кризис дип күпләрнең йокысы качты, тынычлыгы китте, бигрәк тә югалтыр әйберләре булганнарныкы. «Стресс кичергән, больницага кергән» дигән сүзләр йөри. Яшәвенең бөтен максаты байлык булган икән, байлык кимүне, әлбәттә, кеше начар кичерә. Максат Аллаһ һәм Аның ризалыгы булырга тиеш. Бары Ул гына мәңгелек һәм Аның мөлкәте беркайчан да кимеми. «Аллаһ ризыкны киңәйтер, арттырыр», — дигән сүз бар.

«Дөнья кризисы» дип артык кайгырырга ярамый, шәхси кризис яманрак. Бер җирең авыртып, урын өстенә мендең, яки тешең генә сызлый, я тырнак астына шырпы керде, ди — берәр нәрсә күзеңә күренәме соң? Өеңдә тәүфыйксыз, юлдан язган балаң бар, бөтен дөнья гөрләп чәчәк атса да, күзгә күренми бит. Шуның өчен, нинди генә борчу — мәшәкать, зыян, авыру килсә дә, хаталарыбызны эзләргә һәм тәүбә кылырга кирәк. Тәүбә кылу — ул хатаңны тану, хатаң өчен үкенү һәм кабатламау, кеше хакы катнашкан икән — ул кешенең бәхиллеген алу. Аллаһның рәхмәте шулкадәр киң — Ул беркайчан да тәүбә ишеген япмый. Үлгәч, үлемнең билгеләре беленә башлагач, кыямәт билгеләре күренә башлагач, тәүбә капкасы ябыла. Аллаһ Раббыбыз Коръәни Кәримдә: «Берәү гөнаһларыннан тәүбә кылып, Аллаһ ризалыгы өчен гамәлләр кылса, Аллаһ аның әвәлге гөнаһларын изгелеккә алыштырыр», — диде (25:70).  Бүгенге кризисның төп сәбәбе — дөнья экономикасының рибага (банк процентларына) корылуы. Аллаһ Раббыбыз Коръәни Кәримдә: «Әй, иман китергән кешеләр, риба ашамагыз», — дип безне кисәтте (3:130).

Акча, җитештерү тармаклары аша үтеп, продукциягә һәм кабат акчага әйләнергә тиеш. Пәйгамбәребез (с.г.в.) дә акчаны хәрәкәттә тотарга куша. Әмма бүген күп кешеләр акчаны акчага алыштырып, акча эшләү юлына кереп киттеләр, җитештерү тармаклары читтә калды. Авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать тар- магы үз эшчәнлекләрен нормаль алып барырга, эшчеләргә тиешле хезмәт хакы түләргә тиеннәр таба алмаганда, «Беткәнне бетерүдә мең савап», дигән шикелле, аларга кредит тәкъдим иттеләр. Шул ук вакытта миллиард сумнар банктан банкка күчеп, бер тиенгә ярамаган кәгазьгә әйләнеп ятты. Бүген банкларда акча беткән, «кризис», — диделәр. Элек җир шарында күпме акча булган — шул акча калды, берәүдә югалган икән, димәк, икенче берәүнең кесәсенә күчкән. Әгәр җитештерү тармакларына салынган булса, яхшы техника, станокларга әйләнеп, бүген халыкка хезмәт итәр иде. Нефть бәясе 150 долларга җиткәндә, җирле үзидарәләргә, муниципаль берәмлекләргә тиешле акчаны бирмичә, «Үз көнегезне үзегез күрегез», — дип, мәктәпләрне, участок шифаханәләрен ябу, авыл хуҗалыгы продукциясенең бәясен төшерү, шул ук вакытта куллана торган продукция бәяләрен күтәрү — бөтен икътисадны кеше өчен түгел, банклар өчен эшләвен күрсәтә. Банкларның төп функциясе — җитештерү тармагының нормаль эшчәнлеген тәэмин итәргә һәм җитештерү тармагы китергән файдадан табыш алырга тиеш. Товар белән тәэмин ителмәгән акча — акча түгел, буш кәгазь генә. Мәктәпләрне оптимальләштерүне балалар саны кимү белән аңлатсалар, участок больницаларын ябу, район больни- цаларында кайбер бүлекләрне бетерү өчен нинди сәбәп бар, авыручылар саны кимегәне юк бит. Аллаһ Раббыбыз Коръәндә: «Җир һәм аннан табылган байлык бөтен халыкныкы», — дигән икән — табылган байлык халыкка хезмәт итәргә тиеш. Шул байлыкның риба юлы белән банктан банкка күчеп йөрүе кризисны китереп чыгарды да инде. Ризыкны арттыра торган гамәлләрнең берсе — Аллаһка тәвәккәл кылу. Барлык нигъмәтләрнең хуҗасы бары Ул гына икәнен танып, фәкать Аннан гына барлык кирәкләрне сорау.

Әлбәттә, Аллаһ дәүләте чиксез, Ул Үзенең сөекле колларына ни- дер биргәннән аның мөлкәте кимеми. Ул — безнең догаларыбызны Ишетүче һәм җавап бирүче. Әмма без дога кылып сораганда Аның бирүенә һич кенә дә шикләнмичә, ышанып, ихлас һәм саф күңелдән дога кылу кирәк. Фарфор пыяла савыт-са- ба алганда чиертеп карыйлар. Таза булса, чыңлап тора. Күзгә күренер-күренмәс кенә чатнаган булса, чыңламый. Шуның ке бек, «ә бәлки бирмәс, ә бәлки ишетмәс», дигән шик һич кенә дә булырга тиеш түгел. Ибраһим (галәйһиссәламгә) Аллаһның рәхмәтеннән һич шикләнмәде һәм шуның өчен утта аны яндырмады. Чөнки ут ул — Аллаһның мәхлугы. Аллаһ теләмәсә, мәхлук мәхлукка зыян сала ал- мый. Ә менә «ә бәлки салыр» дигән шик-шөбһә безне харап итә. Төшенкелеккә бирелүләр, чарасыз калулар, эчкечелеккә бирелүләр Аллаһны танып, аңа тәвәккәл кылмаудан килә. Нинди генә каза килсә дә, Аллаһка тәвәккәл кылырга һәм Аннан гына ярдәм сорарга кирәк. Әюбнең (галәйһиссәламгә) 14 баласы һәлак булганнан соң, Аллаһ аңа яңадан 26 бала бүләк итә. Дүртенче юл — кәсеп итәргә кирәк. Адәм җәннәттән чыгарылып җиргә куелгач, ризыкны эшләп табу безгә фарыз була. Аллаһ Раббыбыз аңа игенче-лек серләрен өйрәтә. Яз җитә, җирне эшкәртергә, орлык чәчәргә кирәк, сәбәбен иткәч, Аллаһка тәвәккәл кылып, нәтиҗәне сорарга кирәк. Нәтиҗә — Аллаһтан, Аннан гына сорарга, Аңа гына тәвәккәл кылырга, нәтиҗә чыкса, Аңа гына шөкер кылырга кирәк. «Аллаһ бирер әле», дип хәрәкәт итми яту да дөрес түгел. Әлбәттә, без сәбәп итүчеләр генә, нәтиҗә, әйткәнемчә, Аллаһтан, шуңа күрә биргәненә шөкер итү кирәк. Аллаһ Раббыбыз Коръәни Кәримдә: «Әгәр нигъмәтләремә шөкер итсәгез, нигъмәтләремне арттырырмын», — диде (14:7).

Кызганыч, без бүген бик аз шөкрана кылабыз. Югыйсә, тормыш элекке белән чагыштырганда начар түгел. 5, 10, 20 ел элек ничек иде дә, бүген ничек? Ашаган ризык, кигән кием, йорт- җир, машина? Бәлки 30, 40 ел элек әйбәт булгандыр?.. Казан урамында берәү зарлана икән: «Хәерчелек чиктән ашты, машина куярга да урын юк», — дип. Шуның кебек без дә гел зарлануда, кемне генә сүкмибез, гаепләмибез. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Канәгать булыгыз — бай булырсыз», — диде. Ризыкны күбәйтә торган тагын бер гамәл — туганнар, дин кардәшләр белән аралашу. Пәйгамбәребез(с.г.в.): «Туганнары белән аралашып күркәм мөгамәлә кылу кешенең йөзен нурлы, кальбен чиста итәр, ризыгын киңәйтер, кешеләрдә аңа карата мәхәббәт уятыр. Туганнар белән, дин кардәшләр белән араны өзү йөзне каралтыр, кальбне пычратыр, ризыкны тарайтыр, кешеләрдә нәфрәт уятыр», — диде. Әлхәмдүлилләәһ, бүген күбебезнең тормышлар әйбәт, хөкүмәт пенсия дә биреп тора. Әле без кечкенә чакта гына да әби-бабайлар пенсия алмый иде. «Пенсия» дип, 60 нчы еллар башында әбигә 1 капчык, бабайга 1 капчык арыш керттеләр, аларның ул чактагы сөенүләре!.. Бүген бер еллык пенсиягә 1 капчык арыш кына тими бит. Өлкәннәрнең күбесендә ашау- эчү, кием дигән мохтаҗлык юк. Әмма барлык әти-әни дә балалары тарафыннан бер-ике җылы сүз, әз генә

игътибар, ягымлы карашка мохтаҗ. Әти-әниләребез исән икән, ул да Аллаһның нигъмәте, безнең өчен җәннәткә юл. Атнага бер шалтыратып булса да хәлләрен белик, игътибарыбызны, матур сүзебезне жәлләмик. Өйләребез иркен, ләкин иман нуры зәгыйфьләнеп, күңелләр тарайды, суынды. Бер-беребезгә җылы сүз әйтә алмыйбыз. Аралар өзек, мөнәсәбәтләр суык. Югыйсә, әти-әнинең хәлен белү — балалар өчен вәҗиб. Хакыйкатьтә, мохтаҗлыкка төшеп, сиңа ярдәм сорап килүчеләр — Аллаһның рәхмәтен китерүчеләр. Җавап бирмәүче — Аллаһның рәхмәтеннән ваз кичүче. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Бирер әйберегез булмаса, йомшак сүз белән юатыгыз», — диде. Бүген кешеләр эшләрен югалтып, авыр хәлдә калганда, төрле бәла-казалар килгәндә ярдәм итү бигрәк тә мөһим. Зәкәт, гошерләребез дә авыру-сырхаулар, мохтаҗлыкта бу- лучылар, толлар, ятимнәр, дин юлында тырышып хезмәт итүчеләр өчен. Аларга ярдәм итү үзең өчен генә тырышу түгел, үзеңнең нәфесеңнән арттырып, кешеләргә ярдәм итү була. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Күршең ач булса, мул табын артында утыруың дөрес түгел», — диде. Аллаһның хәерсез эше юк, фикерли белгән кешегә һәр нәрсә артында хәер бар, шуңа күрә дә кризис дип төшенкелеккә бирелергә ярамый. Үзебез зарланганча, ярлы икәнбез, безгә кризис бөтенләй янамый, юк байлыкны югалтып булмый, бор- чылабыз икән — димәк, нәрсәбездер бар. Исән-сау икәнбез, сәламәтлек бар икән — тагын ни кирәк?! Ризыкны Аллаһ бирүче, Аңа гына тәвәккәл кылып, Ул куш- канча яшәргә тырышыйк. Гөнаһлага тәүбә кылсак, намазны торгызсак (бигрәк тә җәмәгать намазын), Аллаһка тәвәккәл кылсак, тырышып хезмәт итсәк, булганына шөкер итсәк, дин кардәшләребез, туганнарыбыз белән аралашып, күркәм мөгамәлә кылсак, ятимнәрне, мескеннәрне, фәкыйрьләрне, авыруларны зиярәт кылсак, аларга ярдәм итсәк, ин шә Аллаһ, Раббыбыз ризыгыбызны киңәйтер, кризистан котылу юлларын насыйп итәр. Изге эшләребездә бер-беребезгә ярдәмче булып Ислам динендә яшәргә, дөньядан үткәндә: «Ләәә иләәһә илләллааһү мүхәммәдәррасүлүллааһ», — дип иман белән үтәргә һәм Аллаһның җәннәтләрендә очрашырга насыйп бул- сын. Әмин.

**Җәлил хәзрәт Фазлыев,**
**Татарстанның баш казые,**
**Балтач районы имам-мөхтәсибе**.

## Тарихыбызны барлау – хәерле эш

Чаллы мөхтәсибәте каршындагы Аксакаллар шурасы шәһәр мәчетләре тарихын барлауга үз өлешен кертергә булды. Хәзер мәчет картларыннан истәлекләр җыю бара. Чөнки аларның динебез юлына басу тарихы да шактый үзенчәлекле, гыйбрәтле. Мөхтәсибәтнең Аксакаллар шурасы рәисе Равил хәзрәт Нуруллин болай ди: “Һәрбер мәчеттә шулай җыялар. Аннары истәлекләрне бергә туплап бер китап чыгарырга исәп. Ул, беренчесен тулыландырган икенче басма (беренче басма “Чаллы мәчетләре” исеме астында 2008 нче елны дөнья күрде) булачак һәм шуннан соңгы эшләрне, вакыйгаларны, иганәчеләрне, мөгаллимнәрне үз эченә алачак.”

Бүгенге көндә “Туфан” мәчетенә 11 истәлек язма кабул ителгән. Аларның арасыннан берсен түбәндә укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәбез.

## Гомерем мизгелләре

Мин, Хисамиев Рафис Шәйхетдин улы, 1944 елның 10 мартында Татарстанның Ширәмәт (хәзер Түбән Кама) районы, Ташлык авылында дөньяга килгәнмен. Әтием белән әнием колхозчылар. Әтием балта эшенә, әнием аш-су пешерергә осталар иде. Әтием гарәп, латин, кирилл имляларында укый-яза, әнием гарәпчә укый, әмма яза белми иде. Әнием уразаларны калдырмый тота, намазларын да укып барырга тырыша. Әниебез сәхәргә торгач, миннән дүрт яшькә олырак Рәис абыем белән без дә торабыз. Мичтә ут яна, самовар җырлап утыра, өстәлдә уразага алдан әзерләп куелган тәм-томнар. Сәхәр ашыйбыз ...

Әти намазларын даими укымаса да, аның моңлы тавыш белән Коръән укыганнары әле дә исемдә. Күңелдә иман орлыклары шул чакларда ярала башлагандыр…

Башлангыч белемне авылыбыз мәктәбендә алдым. Бу мәктәп элекке мәчеттә урнашкан, безнең яктагы бердәнбер манарасы балкып утырган мәчет иде ул. Аны кисәргә күп талпынулар булса да, авыл халкы, Аллаһның рәхмәте белән аны саклап калган. Манарага менә торган юл такта белән бүленгән булса да, аның ишеге кайчакларда ачык калгалый һәм без, малайлар, басмалар буйлап югарыга менгәли торган идек. Манара такталарына авылдашлар сугышка киткәндә истәлеккә җыр, шигырьләр, теләкләрен язганнар, кем, кайчан язганы күрсәтелгән. Күпләре кайтмаган ... Хәзер ул мәчет тә юк инде, аның урынында кирпечтән бик матурлап салынган мәчет ай-урагын күктә балкытып утыра. Кайткан чакларымда кереп авылдашлар белән намаз укыйм, уйларга чумып утырам.

Бездән бер чакрым ераклыкта гына булган Шәңгәлче җидееллык мәктәбен тәмамлагач бүтән уку мөмкинлеге булмады. Колхозда төрле эшләрдә эшләдем — ат та җиктем, йөк машинасында төяүче-бушатучы да булдым. Соңрак авылыбыз клубына мөдир итеп куйдылар һәм район культура бүлеге юлламасы белән Алабуга культура -агарту училищесына укырга кереп, аны тәмамлагач Чаллы шәһәренең Үзәк урамында урнашкан культура йортында сәнгать җитәкчесе булып эшләдем. Ә инде КамАЗ төзелеше башлангач “Спецстрой” трестының матбугат үзәгендә озак еллар рәссам-бизәүче булдым. “Тукайагрострой”да эшләгәндә Биклән авылы мәчетен төзүдә катнашуым, аның нигезендә, диварларында, манарасында минем дә күңелем вә кул җылым калуы бүген дә җанымны җылытып тора.

Без бит динсез-денсез ил-дәүләттә туып, советча тәрбияләнгән буын. Үзгәреш җилләре исмәсә, ул динсезлек сөреме һаман җаннарыбызны агулап торыр иде. Аллаһның рәхмәте белән галәмәт зур, мәңге какшамас сыман тоелган Совет империясе таркалып, ирексезләп тотылган республикалар ирек алып, үзләренең бәйсез дәүләтләрен төзеделәр. Безгә дә, тулы ирек булмаса да, иркенлек бирелде, дингә юл ачылды.

Безнең гаиләдә намазга басучы беренче кеше хәләл җефетем Флүрә булды. Әлбәттә, намаз уку җиңел генә бирелми, аның өчен байтак кына тырышырга, Коръән-Кәримнән аятьләр, кыска сүрәләр, догалар өйрәнергә-ятларга, намаз кагыйдәләрен үзләштерергә кирәк. Әмма Аллаһ Раббыбыз күңеленә иман нуры иңдерсә барсын да булдырасың, зиһенең ачыла, әкренләп барсы да хәтереңә, күңелеңә сеңә бара. Форсат булган саен, эшкә барганда-кайтканда аять-сүрәләрне, догаларны гел кабатлап, ятлап йөрдем. Минем иң бәхетле көнем 2006 елның 17 апреле — шул көнге иртәнге намаздан башлап, биш вакыт намазларымны калдырмый вакытында үтәп барырга тырышам.

Уразаларны намаз укый башлаганчы, байтак еллар элек тота башлаган идек — үзем дә, хатыным да, ике кызыбыз да. Инде оныгыбыз да ураза тота, намаз укый, Аллаһыга шөкер.

Фани дөнья бәхет-шатлыклардан гына тормый шул, аның борчу-кайгылары да җитәрлек. Намазлар укый башлагач бергә озак яшәү насыйп булмады — Аллаһы Тәгаләнең тәкъдире белән шул ук елның 2 нче июлендә хәләл җефетем вафат булды. Инде Раббым Аллаһ сабырлыклар, тәкъвалыклар биреп, туры юлдан тайпылмыча яшәргә, кимчелек-хаталарыбызны кичереп, укыган намазларыбызны, тоткан уразаларыбызны, чалган корбаннарыбызны, кылган догаларыбызны, теләгән теләкләребезне кабуллардан кылып, барча газизләребез, якыннарыбыз белән җәннәтләреңдә бергә булырга насыйп итсәң иде. Әмин.

Мәчеткә, җомга, тәрәвих намазларына соңрак — 2009 нчы елның 25 декабреннән йөри башладым. Аңа кадәр сәламәтлегем мөмкинлек бирмәде. Саулык чамалы булу хаҗ сәфәреннән дә тыеп тора.

Сорамаслар: “Кәфенең ник бик фәкыйрь?”
Иманыңны тикшерер Мөнкир, Нәкир.
Исән чакта намазларны калдырма.
Ураза тот, телеңдә булсын зикер!

**Чаллы шәһәре.**

*Укучыларыбыз иҗаты*

## Галимҗан Баруди (Галиев)

Галимҗан Баруди – галим, педагог, сәясәтче,
Күп дәреслекләр авторы, җәмәгать эшлеклесе.

Авыл аның туган җире, әмма үсә Казанда,
Күлбуе мәдрәсәсендә белем ала ул анда.

Аннан китә Бохарага, ул “Мир-гарәп”тә укый,
Җиде еллап гомерен шунда белем алуга
багышлый.

Казанга кайткач ул – мулла дүртенче мәхәлләдә,
Бик кыска вакыт эчендә ул танылып өлгерә.

Шуңа аны бик шатланып, имам итеп куялар,
Яңа мәдрәсә ачарга аңа рөхсәт бирәләр.

Ә әтисе – Мөхәммәтҗан, һәм аның хөрмәтенә
“Мөхәммәдия” исеме – әнә шуңа бирелә.

Педагогик эшчәнлеккә багышлый бар ормышын,
Киңәйтә, төзекләндерә мәдрәсәнең бинасын.

Укыту программаларын Г.Баруди яңарта,
Үзе дәреслекләр яза, бастыра, һәм укыта.

Китап һәм хезмәтләренә яшерен имза куя,
Иң элек “Г.Пороховой”, аннан “Баруди” була.

“Мөхәммәдия” ул чорда җәдитчә белем бирә,
Шушы төбәктә иң эре үзәккә әверелә.

“Әд-дин вәл-әдәб” журналы чыга башлый шул
чорда,
Мөһәррирлек вазыйфасын үти Баруди анда.

Хакимият тарафыннан шушы журнал тыела,
Ике елдан шуңа күрә чыгару туктатыла.

Панисламизмда гаепләп сөргенгә үк сөрелә,
Ике елдан кайткач эшли, журнал да чыгарыла.

Чит илләргә сәяхәтне Г.Баруди еш кыла,
Истанбулда, Каһирәдә, Мәдинә, Мәккәдә була.

“Мөхәммәдия”дә эшли – утыз биш ел мөдәррис,
Мөселманнарның сәяси тормышында да актив.

Ул “Иттифак әл-мөслимин” Үзәк комитетының
Әгъзасы итеп сайлана, абруе бик зур аның.

Бик зур була, бик бай була Шәрекъ
халыкларының
Китапларыннан җыелган китапханәсе аның.

Алтмыш яше тулгач бара Мәскәүгә корылтайга,
Үзәк диния нәзарәте мөфтие итеп сайлана.

Биш ел ярым мөфти булып, җиңен сызганып
эшли,
Күп изге гамәл башкара, ару-талуны белми.

Киләчәккә планнары әле аның күп була,
Мәскәү каласында баргач, ул кинәт вафат була.

Быел аның тууына була бер йөз алтмыш ел,
Дин галиме һәм сайланган беренче мөфти дә ул.

Онытмыйлар хезмәтләрен, ул халыкның исендә,
Галимҗан Баруди елы быел шуның өчен дә.

**Асия Корбангалиева,**
**Әгерже шәһәре.**

*Хаҗия язмалары*

# Хаҗга – автомашинада

Тәүбә итеп туры юлга басып Аллаһ Тәгаләнең кушканнарын һәм тыйганнарын үтәп яши башлаганга да 20 ел узып киткәне сизелми дә калды. Шушы бәхетле тормыш шатлыгын сезнең белән дә уртаклашасым килә. Аллаһ Тәгаләнең хикмәте белән, бәлки, кемгәдер туры юлга басарга насыйп булыр. Миңа туры юлга басуыма ураза этәргеч булды. Ураза ае керер алдыннан дога кылып Раббымнан: "Үзеңә гыйбадәт кылыр өчен көч-куәт, дәрт һәм исәнлек-саулык насыйп ит,"- дип сорадым. Ураза аенда ураза тота башладым: күңелләрем күтәрелде, үземдә ниндидер бер сихри көч тойдым. Иптәшемне дә уразага ниятләп ураза тотарга үгетләп карадым. "Миннән булмый әле, син үзең генә тот инде, мин каршы түгел,"- диде. Намаз китаплары сатып алдым, догалар өйрәндем. Намаз укыр өчен күпме догалар өйрәнергә кирәк. Боларны өйрәнеп бетереп булыр микән? дип курка калдым. Өйрәнә торгач Аллаһы Тәгалә Үзе ярдәм бирә икән. Барсын да тиз өйрәндем, әлхәмделилләһ. Намазны да укый башладым. Шушы елны үзебезнең яндагы "Нур-Ихлас" мәчетенә Коръән укырга өйрәнергә йөрдем. Укытучым инде мәрхүмә Тәслимә ханым иде. Укыганнарым аңа да дога булып барсын. Укуымның өченче елында — 2000 елны имтиханнарга әзерләнә идек. Шул чакны иптәшем һәм иптәшемнең абыйсы белән хаҗга барырга ниятләдек. Иптәшемә дә Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп яшәргә насыйп булды. Укырга кергәч, Коръән укый башлагач, Аллаһы Тәгаләдән тәһәҗҗуд намазына торып елый-елый: "Бастыр инде иптәшемне туры юлыңа, арындыр инде шушы хәрам ризыклардан. Үзеңә ихлас күңелдән гыйбадәт кылып яшәргә насыйп ит инде,"- дип сорадым. Әлхәмделилләһ, Раббым догаларымны кабул итте — 1998 елдан бирле ул да гыйбадәттә. Үзлегеннән Коръәнне укырга да өйрәнде. Аңламаганнарын миннән сорады. Гыйбадәт кылып яши башлагач тормышлар үзгәреп китте, дөньялар яктырды, өйдә тынычлык, татулык, бәрәкәт. Боларны барсын да сөйләп бетерерлек түгел. Менә шуннан соң инде 2000 елда үзебезнең машиналарыбыз белән хаҗга барырга ниятләдек — хәстәрләрен күреп җыена башладык. Виза алырга баргач безгә виза бирмәделәр. Һәрбер кеше үз машинасы белән барса, анда болай да машиналарга урын юк, диделәр. Бер машинада һич югы 10 кеше булсын, диделәр. Без кайгыра башладык. Иптәшем абыйсы белән Казанга киттеләр, берәр нәрсә булмасмы? дип. Анда күпме сорашып, ничә мәчеткә кереп, бер нәрсә дә булмый инде, дип кайтырга чыкканда Рамил хәзрәт Юнысов белән очрашалар. Иптәшем: "Ул үзенең бөтен эшен ташлап, безнең белән сөйләшеп үзенең киңәшләрен бирде,"- диде. Ул үзе дә 2000 елда бер автобус белән Казаннан хаҗга бара иде. "Безнең автобус тулы. 3 кеше өчен тагын бер автобус яллап булмый инде, алай да мин сораштырырмын, берәр нәрсә килеп чыкса сезгә шалтыратырмын,"- дип телефон номерын алып калган. Иптәшем Казаннан кайткач: "Бернәрсә дә булмас ахрысы, Казаннан баручы автобус та тулы,"- дигәч, күз яшьләремнең агуын туктатып булмады. "Йә, Раббым, шул хәтле хаҗга барасым килә, насыйп ит инде,"- дип сорый башладым. Шул ук көнне кич белән Рамил хәзрәт шалтыратты. "Менә шушы телефон буенча шалтыратыгыз, Буадан Фәһим хәзрәт кешеләр җыя,"- диде. Без шундук Фәһим хәзрәткә шалтыраттык. Ул: "Иртәнге сәгать алтыга документларны китереп җиткерегез, сәгать 8 дә виза алырга Мәскәүгә китәбез,"- диде. Иптәшем абыйсы белән төнге 1 дә чыгып киттеләр. Әлхәмделилләһ, насыйп булгач, 2 атна



Ихрамга кергәч – март 2000 ел;

каранып йөргәндә, безне милиционерлар арестовать итеп алып киттеләр. Башлыклары килгәнче көтеп тордык. Янәсе, ваххабистларны тоттылар. Башлык безнең каян килүебезне һәм кая баруыбызны сорады да, безне арестовать иткән кешеләрне аты-юлы белән сүгә башлады. Гафу үтенеп, безне озатып калдылар. Без шулай итеп тагын бер көнне диярлек югалттык. Төркмән чигенә килеп җиттек. Анда машиналар чираты, таможныйда кешесе юк. Машинадагылар: "Өч көн көтеп утырабыз,"- диделәр. Фәһим хәзрәт миңа: "Аллаһ Тәгаләдән сорап 2 рәкәгать намаз укы әле,"- диде. Мин намаз укып дога гына кылдым, безне чыгарырга кешесе дә килде. Иң алдан безне чыгардылар. Аннан соң инде бер җирдә дә тукталып тормыйча Иран чигенә җиттек. Иранга кердек. Аның чигендә бөтенләй башка хәл: чисталык, кешегә уңай мөнәсәбәт. Безнең бер кая чыгып йөргәнебез булмагач исебез китте. Иранда безне үз өйләренә алып кайтып, ашатып-эчертеп, анда кунып юлга кузгалдык. Иранда юллар шундый: барасың да, барасың. Юллар тау башларыннан үтә. Тау башына менеп җиткәч анда кафе кебек җирләр бар. Шунда чәй эчеп, ашап алырга дип туктаган идек. Безнең янга автобус килеп туктады. Карыйбыз — безнең номерлар. Алар да ашап-эчеп алгач без бергә кузгалдык. Намазларны юлда мәчетләрдә туктап укырга тырыштык. Ираннан Гыйракка кердек. Гыйракта өйлә намазын укыр өчен бер мәчеткә туктадык. Анда тәһарәтләр алып чыкканда документларны урлый яздылар. Ярый, Фәһим хәзрәт күреп өлгергән. Раббем безне яклады. Азан вакытын да, азанны да монда дөрес әйтмиләр, Галине кушалар, диделәр. "Әйдәгез, кырда укырбыз,"- дип кузгалып киттек. Юлда барганда безгә юл күрсәтеп торучы: "Менә бу якка!"- дип безгә күрсәтте. "Юк, нишләп ул якка булсын, бу якка бит,"- дип без тыңламыйча киттек. Намазны укыганнан соң бераз баргач туктап сорадылар. Безгә кире китәргә куштылар. Шунда инде менә мәчеттә намаз укымыйча китүебезнең сәбәбе: 80 км. барганбыз адашып, кире кайтуыбыз белән 160 км. булды. Ә безнең Казан автобусы бездән алда Сөгуд Гарәбстаны чигенә җитеп, таможняларны үтеп Мәдинәгә киткәннәр иде. Без алар белән автобуслар стоянкасында гына күрештек. Без иң кыска юл белән барабыз, тизрәк барып җитәбез дигән кешеләр 9 көн бардык. Ә Казан автобусы 7 көн. Мәдинәдә бер атна тордык. Автобуслар тукталышында торганда минем яныма бер хатын килде. Кара киемнән, бите күренми. Минем белән татарча исәнләшеп сөйләшә башлады. "Апа сез Казаннанмы?"- диде. Мин инде каян икәнлегемне әйткәч, ул, Казаннан автобус килергә тиеш иде, алар сезнең белән килмәделәрме? дип сорады. "Шушы автобуста әтием килергә тиеш иде хаҗ кылырга,"- дигәч, мин Фәһим хәзрәтнең аларны эзләп китүен, аларның бездән алда килгән булырга тиешлеген әйттем. Ул: "Апа, сезнең торырга урыныгыз бармы Мәдинәдә?"- дип сорады. "Мин бернәрсә дә белмим,"- дигәч: "Хәзрәт килгәч беркая да китмәсен, яныгызга бераздан килербез,"- диделәр. Әңгәмәдәшебез Роза исемле икән. Әлки районыннан булып чыкты. Мисырда торалар икән. Алар безне кунакханәдә бушлай бер атна тоттылар, ашаттылар, эчерттеләр. Әл-Хәрәмгә бергә йөреп Мәккәгә дә бергә кузгалдык. Ихрамга кереп Мәккәгә кич булгач килеп җиттек. Монда безне каршы алырга тиешләр иде. Каршы алучы озак килмичә торгач безне озатып баручы солдат машинаны стоянкага илтеп куйдырды. Үзебез әл-Хәрәмгә киттек. Без әл-Хәрәмдә вакытта Фәһим хәзрәт торыр урын эзләргә дип киткән иде. Табып кайтты. Без 4 катлы йортта тордык. Ул йорт таджик кешесенеке булып чыкты. Үзе вафат булган. Балаларына әйтеп калдырган, кемнәр безнең яктан хаҗ кылырга киләләр, шуларны бәя алмыйча тот дип.

**Дәвамы бар.**



**Гарәп чүлендә - март 2000 ел;**

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы**
**ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррире**
**Хәлил ШӘРИФ**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газетабыз мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучылар сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җаваплар бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 2000.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, алай дабулмаса башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетабызны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы,**
**Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**26 гыйнвар16 сәг.,**
**фактта 26 гыйнвар 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**